
# УҺУ

Декабрь, 2018 ел

*«Замандаш» укучылар оешмасының электрон газетасы*

Бусагада – ЯҢА ЕЛ! Без бәхет һәм үкенеч, шатлык һәм югалту булган узган елны искә төшерәбез. Һәрберебезнең алар үзенеке һәм без аларны истә тотачакбыз. Яңа елда шатлыклы очрашулар, бәхетле елмаюлар, куанычлы мизгелләр күп булсын! Бәйрәм белән, дустым! Ышанычың, йөрәгеңнең серле бер почмагында сакланган өметең тормышка ашсын, бәхетең мөлдерәмә тулып торсын. Гомерең шатлыклы, куанычлы, мул ризыклы булсын, сәламәтлектә узсын. Шатлыклы хәбәрләр, бәхетле көннәр узган елдагыдан да күбрәк булсын, көнчелсезлекләр иске елда калсын!






Җиргә тагын карлар ява инде,
Җир төренә тагын аклыкка,
Җир яшерә үзенең гөнаһларын,
Җир күмелә сафлык, пакълеккә.
(Р. Вәлиев)

Табигатьтә дүрт ел фасылы бар: кыш, яз, җәй, көз. Аларның һәрберсе үзенчә матур, үзенчәлекле, сокландыргыч. Алтын көз үтүгә, салкын бураннары, ап-ак күбәләк-күбәләк карлары белән туган ягыма кыш килә. Ул – дөньяның иң салкын, шул ук вакытта иң чиста, саф, җемелдәшеп җиргә яуган кар бөртекләренә күмелгән вакыты. Урамда, бөтерелә-бөтерелә, ак чәчәкләр ява. Агачлар, өй түбәләре – барысы да ак юрган астында кала. Энҗе кар бөртекләре ява башлау белән, бар кеше дә Яңа елны көтә башлый. Кышның саран саргылт кояшы карлы бураннар белән алмаша, ә бураннарга алмашка каты суыклар килә - мөгаен, кышның гүзәллеге шундадыр.

Кышның иң матур мизгеле – кышкы бизәкләрдер ул. Авылның кышкы матурлыгы шул бизәкләрдә бит инде. Үзләренең яшел киемнәрен салган агачлар кышкы ак киемгә киенгән. Авылдагы йортлар, агачлар, юллар ап-ак кар астында кала. Кышкы урман, кыр һәм болыннар бик матур. Анда кар да күбрәк, чистарак һәм һавасы да сафрак. Урманда рәт-рәт булып үсеп утырган чыршы, наратлар кардан ак шәл салганнар…

Кышның тагын бер матур ягы – су буе. Боз астында челтер-челтер килеп су агып тора.



Без кыш айларын бик яратабыз, чөнки болар барысы да тик кыш көне генә булалар. Кышның үзенә күрә бер бизәкләре ул. Кыш – күңелләргә ял бирә. Кыш – табигатьнең аклыкка төренеп ял иткән чагы ул.

9Б сыйныфы укучылары

## «День матери» в 8-б классе

Особое место, среди многочисленных праздников, отмечаемых в нашей стране, занимает - День матери. Это праздник, к которому никто не может остаться равнодушным, это праздник вечности: из поколения в поколение для каждого человека мама – самый главный человек жизни. В этот день хочется сказать слова благодарности всем Мамам, которые дарят детям любовь, добро, нежность и ласку.

28 ноября 2018 года в 8-б классе прошел праздник, посвященный международному Дню Матери. Класс был полон гостей, среди них - мамы, мамы мам (бабушки), ученицы и классный руководитель. Ведущие праздника Зиля Мухаммадиева и Адиля Шайхутдинова тепло приветствовали всех гостей и поздравили с праздником. Им удалось создать в классе атмосферу доброжелательности и хорошего настроения.

В исполнении восьмиклассниц звучали песни о мамах, которые «зажгли» всех зрителей. Поддержали их и внесли свой «огонек» в настроение публики все девочки класса современными танцами. Матери с восхищением наблюдали за выступлениями своих детей и от души радовались. После каждого выступления не стихали овации. Завершилось мероприятие общей дискотекой. В течение праздника были показаны различные презентации и видеоролики, посвященные Дню Матери.

В классе были развешаны газеты, шары, была оформлена выставка декоративно-прикладного творчества «Золотые мамины руки», на которой экспонаты были выполнены мамами нашего класса. Особенно привлекли внимание платья, сшитые собственными руками мамы Лины Гарифуллиной. Перед праздником все мамы получили поздравительный буклет, который дети сделали своими руками, и розу. После каждого конкурса участники награждались грамотами. Уходили мамы с особым чувством – одухотворения и легкости. Праздник выдался, что называется, на славу. Обучающиеся подарили, замечательный концерт, который получился особым, действительно ярким и добрым!



Говорим «Спасибо»!
Мы, родные, Вам.
Ведь Земля красива
ДОБРОТОЮ МАМ!

## Безнең сыйныф

Без, 7 а сыйныфы укучылары үзебезнең сыйныф тормышы белән таныштырып китәргә булдык. Без дус, тату, бердәм сыйныф. Сыйныф җитәкчебез Айгөл Раузидовна һәр атна саен кызыклы сыйныф сәгатьләре, төрле чаралар үткәрә. Ул класс сәгатьләрендә илдә, республикада, районда һәм мәктәптә булган төрле вакыйгалар, чаралар турында бик күп мәгълүмат бирелә. Класс сәгатьләре кысаларында һөнәр сайлау буенча да даими эш алып барыла. Шулар арасында аеруча истә калганнары ...Госман абыйның кул эшләре, бигрәк тә үзе ясаган авыл коесы, тегермән, җигүле ат; Альбина апаның мастер- класслары; авыл советы депутатлары белән очрашулар булды. Октябрь аенда 5-7 сыйныфлар арасында “Көзге бал” кичәсе уздырылды. Бәйрәм квест формасында оештырылган иде. Бу квестта безнең сыйныф 1 нче урын яулады. Бу уңышларга ирешүдә сыйныф җитәкчебез Айгөл Раузидовнаның хезмәте бик зур. Мәкаләбезне тәмамлап, шушы шигырь юлларын язып үтәсе килә:



Дусларымны күрүгә,
Йөздә шатлык кабына.
Һәрбер уку елында
Яңа дуслар табыла.

Безнең бердәм сыйныфны
Танырсыз бер күрүдә
Укуда да, ярышта да
Без алдынгы урында.

## *Яңа ел әңгәмәсе*

Без зарыгып көткән Яңа ел бәйрәме якынлаша. Шул уңайдан быел мәктәп тормышына аяк баскан I сыйныф укучыларына мөрәҗәгать иттек.

**Камил Галимов:**

-Үткән ел синдә нинди тәэсирләр калдырды?

-Үткән ел мин бик яхшы билгеләренә генә укыдым. Лагерьда каникулларыбызны бик күңелле итеп үткәреп җибәрдек.

-Киләсе елдан син ни көтәсең?

-Бик яхшы билгеләргә укуымны дәвам итәргә телим.

**Диана Ермалаева:**

-Үткән ел синдә нинди тәэсирләр калдырды?



-Лагерьдагы уеннар, лагерь гомумән миндә бик яхшы тәсирләр калдырды, бу ел миндә шуның белән истә калды.

- Киләсе елдан син ни көтәсең?

-Киләсе елда 4-5ле билгеләренә генә укырга телим.

**Динә Гомәрова:**

-Үткән ел синдә нинди тәэсирләр калдырды?

-Бу ел мин күп кенә чараларда катнаштым, алар миңа бик ошады.

-Кыш Бабайга хат яздыңмы әле?

-Әйе, яздым.

-Аннан нәрсә сорадың?

-Чана.

- Киләсе елдан син ни көтәсең?

- Күп итеп бишлеләр аларга, әйбәт укырга телим.

**Зифа Бариева:**

-Үткән ел син Кыш Бабайдан нәрсә сорадың?

-Чана.

-Бүләк иттеме?

-Әйе.

- Киләсе елдан син ни көтәсең?

-Мин киләсе елда укуда уңышларга ирешергә телим.

**Данияр Газизуллин:**

-Үткән ел синдә нинди тәэсирләр калдырды?

-Безнең өйдә ремонт ясавыбыз белән истә калды, шулай ук яхшы билгеләргә генә укыдым.

-Уку авырмы?

- Әйе

- Ә кайсы рәхәтрәк мәктәптә укумы, әллә балалар бакчасына йөрүме?

- Балалар бакчасына йөрү.

- Ә ни өчен?

- Чөнки анда йоклаталар, төрле уеннар уйнаталар.

- Кыш Бабайдан нәрсә сорадың?

- Хоккей клюшкасы белән шайба сорадым.

- Киләсе елдан син ни көтәсең?

- Әгәр дә мин бу уку елын яхшы гына тәмамласам, туган көнемә әтием велосипед бүләк итәм диде. Шуңа күрә мин бу уку елын яхшы билгеләргә генә тәмамларга телим.

11 сыйныф укучысы **Хадиев Газизгә** дә мөрәҗәгать иттек:

-2018 ел ни белән исеңдә калды?

-Миңа 2018 ел мәктәп президенты постын бик булдыклы егеткә тапшыруым белән исемдә калды.

-2019 елдан ни көтәсен?

-Мин 2019 елдан бары тик яхшылыклар, уңышлар, яңа дуслар, кызыклы танышулар көтәм. Яңа елда барыгызга да бәхет-шатлык, тазалык-саулык, саф мәхәббәт телим.

**Гөлшат Самигулловна:**

-2018 ел сездә нинди тәэсирләр кадырды?

-2018 ел бик матур, шатлыклы вакыйгаларга бай ел булды. Үткән елда шулай ук минем гаиләм өчен сагышлы вакыйга да булды: кызым гаиләсе белән еракка китте. Эштә барысы да әйбәт, уку-укыту эшчәнлеге бик яхшы бара. Әти-әниләр республика күләмендә җиңү яулап кайтты. 2018 елны уңышлы һәм матур ел булды дип саныйм.



-Сез киләсе елга нинди өметләр багълап торасыз?

-Киләсе ел тыныч булсын. Беребезнең дә гаиләләребездә, эштә кайгылар булмасын. Укучыларга, хезмәттәшләремә исәнлек-саулык, бәхет телим.

**Гатауллина Адилә:**

-2018 ел ни белән исеңә кереп калды?

-2018 ел бик актив, хатирәләргә бай ел булды. Бигрәк тә Турция исемдә калды, чөнки мин бик күп яңа дуслар таптым. Алар Казахстаннан һәм Турциядән. Хәзерге вакытта да без алар белән интернет челтәре аша сөйләшеп торабыз.

-Яңа елдан ни көтәсең?

-Яңа елдан бары тик уңыш һәм бәхет көтәм. Һәм бөтен кешегә дә шушы теләкләрне телисем килә. Дус булыйк! Бергә булыйк!

Әңгәмәне 10 сыйныф укучылары Кабирова Динә һәм Шарифуллина Фирүзә үткәрделәр.

# *Укучыларыбыз иҗаты*

**Тимеръаяк**
Азатта  бар,
Алмазда бар,
Ә миндә - юк.
Алар чаба,
Алар оча...
Мин торам
тик.
Менә эти
Алып кайтты
Тимеръаяк!
Өр яңаны,
Чип чистаны -
Тибә йөрәк.
Мин дә чабам,
Мин дә очам,
Алар кебек!
Йөзә генә
Боз өстеннән
Тимеръаяк!
Борханов Илнур, 6 нчы А
сыйныфы укучысы.



**Әнием мине ярата.**
Әнием белән бергә,
Һәркөн күңелле үтә.
Иркәләп ул уята,
Чәчләремне тарата.
Тәмле итеп ашата,
Әнием мине ярата!

Әнием белән бергә
Һәр көн файдалы үтә.
Мәктәптәпкә ул озата,
Өй эшләрен аңлата,
Кирәк булса укыта,
Әнием мине ярата!

Нәбиева
Әлфинә, 6
нчы А
сыйныфы
укучысы.



**Бәйрәмне котә тычкан.**

Ап-ак кышлар килгәндә,
Яңа еллар житкәндә
Бәйрәмнәрне көткәндә,
Ак тунын кигән куян.

Куянны тычкан күргән
Озак кызыгып йөргән.
Аның да Кыш бабай янында
Актан йөрисе килгән.

Ап-ак онга чумган да,
Чыккан ак тычкан булып
Хәзер безнең белән бергә
Бәйрәм көтә куанып.

Салихов Наил, 6 нчы А
сыйныфы укучысы.

---

**Яңа ел бәйрәмендә**

Бүген Яңа Ел була,
Шатлыктан күңелем тула.
Кыш бабай килеп җитә,
Күңелем бүләк көтә.

Куана-куана шигырь сөйлим
Кыш бабайның үзенә.
Ин яхшы бүләген бирә,
Бабай минем үземә.

Абдуллина Гөлинә, 6 нчы А
сыйныфы укучысы

**Кыш килгән**

Әй, күңелле,әй,рәхәт –
Бүген безгә кыш килгән!
Соры күлмәге өстеннән,
Ап-ак җылы тун кигән.

Шатлыгымнан түзәлмадым,
Йөгереп чыктым урамга
Рәхәт тә соң йөрүләре,
Урамдагы буранда.

Нәбиева Әлфинә, 6 нчы А
сыйныфы укучысы.

**Салкын кыш**

Ак буранлы салкын кыш
Чеметкәли битләрдән.
Урамда һәрбер кеше
Җылы киемнәрдән .



Ак буранлы салкын кыш
Катырып куйган елганы.
Тимераяклы яшь дуслар
Урап алган елганы.

Ак буранлы салкын кыш
Төшергән бизәк тәрәзгә.
Урам тулы бала - чага
Салкын түгел,ди, безгә.
Ак буранлы салкын кыш
Хакимлек итә табигатьтә.
Кыш айлары үтсен
Бары бәхет – шатлыкта.

Ак буранлы салкын кыш
Алып килсен куаныч.
Ап - ак карлар төсле
Явып торсын куаныч.
**********************

Шайхетдинова Инзилә,
11сыйныф укучысы

**Мәктәп тормышыннан**

Булып үтте бик кунелле,
Кызыклы кичке чара.
Куангандыр анда килгән
Кешеләрнен барсы да.

Укытучыларга багышлап
Язамын бу шигырьне.
Утырып бер кабинетта,
Күрмәделәр кичәне.

Башта караоке булды,
Кызлар торкеме жинде.
Аннары ин кызыклысы:
Бию вакыты җитте.

Биеде СПТУлар да,
Үзебез дә биедек.
Бию коенэ кушылып
Жырладык һәм колештек.

Рәхмәт укытучыларга,
Зур рәхмәт "Хыял"га да!
Дискотека матур үтте,
Булсын шулай тагы да.

9 А сыйныфы укучылары



## *Укучыларыбыз иҗаты*

### Кышкы куаныч

Кыш. Җир өстенә ап-ак юрган ябып,кешеләргә шатлык өстәп кабат кыш җитте. Кыш җитүгә балалар сагынып Яңа елны көтә башлыйлар, Кыш бабайга бүләк сорап хат язалар.

Бездә исә Яңа елга әзерләнә башладык. Бу арада мәктәп яны шау-гөр килеп тора.Әти-әниләр, балалар,укытучылар кардан сын ясау белән мәшгуль. Нинди генә сыннар юк монда. Кыш бабай, Кар кызы, аю, бүре, төлке. Күзнең явын алырлык сыннар арасында әкият геройлары гына да ни тора!

Менә шулай ел саен мәктәп ямен матурлап,бизәп каршы алабыз без Яңа елны.Үзебез ясаган кар сыннары бик кадерле. Шуңа без аларны саклап кына торабыз. Алар безне мәктәпкә килгәндә каршы алалар, озатып калалар. Мәктәп тирәсендә шундый матурлыкны күргәч күңелләр күтәрелеп китә.



### Әтиемнең Туган көненә!

Әтиемнең туган көненә
Бүләк итәм шигырь юлларын.
Иң беренче телим бәхетләр
Озын гомергә чәчәк яуганын.
Иң кадерле, иң яраткан
Әтиебез бер генә
Сау-сәламәт яшә әти
Яратып һәр берсен дә
Котласын дус-ишләрең
Бик матур шигырь белән
Ходай бирсен мең бәхетләр
Иң кадерле көнеңдә.
Оста түгел шагыйрьлеккә
Шуңа килми уйлары
Яратабыз сине гомерлеккә
Кадерләп еллар буйлары.

7б сыйныфы укучысы
Яруллина Динә

### Тукаебыз

Тукайны без кечкенәдән ,
Олылыйбыз,зурлыйбыз.
Әле һаман моңлы итеп,
Туган телне җырлыйбыз.
“Су анасы”,”Шүрәле”се
“Кәҗә белән сарык”ы
Тукайның һәрбер шигыре
Халыкның горурлыгы.
Тукаебыз мәңгегә дип
Җырлыйбыз без мәдһия
Тукайның изге рухына,
Милләтебез баш ия.

7б сыйныфы укучысы Гаязова Нәзилә

## *Хәбәрләр, яңалыклар*

22 декабрьдә Норма урта мәктәбенең инженер группасында белем алучы укучыларны котларга Казан шәһәренең Совет районы инженер лицее җитәкчеләре, укытучылары килде. Укучыларны инженер классына кабул итү тантанасы уздырылды.





“Игенче” ҖЧҖ призына хоккей ярышында мәктәпнең 2008-2009 елларда туган яшь хоккейчылар командасы III урынны алды.

Мәктәбебезнең “Радар” отряды яшь юл инспекторларының район конкурсында “ Иң яхшы отряд портфолиосы” номинациясендә җиңүче.



“Ромашка” мәктәп яны лагеры Республика лагерьлар конкурсында көндезге лагерьлар арасында беренче дипломант булды. Котлыйбыз!





“Халык зур ул, моңлы ул” зонаара конкурсыннан мәктәбебез укучылары 3 диплом белән кайттылар.

Мәктәбебезнең башлангыч сыйныф укытучысы Абдуллина Эльмира Илфак кызының шәхси сайты Бөтендөнья күләмендә үткәрелгән “Белем җәүһәрләре” бәйгесенең “Гаилә һәм башлангыч белем җәүһәрләре” номинациясендә 2нче урынны алды.

